ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.12.2017 ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3277**

2018 елда Зеленодольск муниципаль районының предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары арасында «Сәламәтлек» спартакиадасын үткәрү турында

Зеленодольск муниципаль районы халкының сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен шартлар тудыру һәм спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018 елда Зеленодольск муниципаль районының предприятие, учреждение һәм оешмалары арасында «Сәламәтлек» спартакиадасын (алга таба - Спартакиада) үткәрергә.
2. 2018 елда Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары арасында «Сәламәтлек» спартакиадасын үткәрү турындагы нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә 2018 елда Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары арасында «Сәламәтлек» спартакиадасын уздыру турында массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәэмин итәргә.
4. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсенә 2018 елда Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары арасында “Сәламәтлек” спартакиадасын әзерләүнең һәм үткәрүнең гомуми җитәкчелеген тәэмин итәргә.
5. Предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга 2018 елда Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары арасында «Сәламәтлек» спартакиадасының аерым төрләрен үткәрүне әлеге карарның кушымтасы нигезендә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Г.Н. Нуриевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

Кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
26.12.2017 ел, №3277

# 2018 елда
# Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары арасында «Сәламәтлек» спартакиадасын үткәрү турында
# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1.МАКСАТЛАР ҺӘМ БУРЫЧЛАР.

- сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;
- сәламәтлекне саклау һәм ныгыту;
- физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү;
- иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау.

## 2. ҮТКӘРҮНЕ ҖИТӘКЛӘҮ.

Спартакиаданы әзерләү һәм үткәрү буенча гомуми җитәкчелек Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла

Спартакиаданы турыдан-туры үткәрү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе тарафыннан расланучы судьялар коллегияләренә йөкләнә.

## 3.СПАРТАКИАДА ПРОГРАММАСЫ ҺӘМ ҮТКӘРҮ СРОГЫ.

### *1. ЧАҢГЫ ЯРЫШЫ.*

Ярышлар «Маяк» ДАУ базасында, гыйнвар-февраль айларында уздырыла. Команда составы 10 кеше (6 ир-ат,4 хатын-кыз). «4 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе үткәрү өчен җаваплы.

### *2. АРМРЕСТЛИНГ.*

Ярышлар 4 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ, февраль-март көннәрендә уздырыла. Команда составы 6 кеше (4 ир-ат, 2 хатын-кыз). «Ледокол» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ һәм «4 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ үткәрү өчен җаваплы.

### *3. ДАРТС.*

Ярышлар «Исток» яшьләр клублары берләшмәсе» МБУ уздырыла, март. Команданың составы 10 кеше (6 ир-ат, 4 хатын-кыз). «Бригантина» 6 нчы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ һәм «Исток» яшьләр клублары берләшмәсе» МБУ үткәрү өчен җаваплы.

***4. ӨСТӘЛ ТЕННИСЫ.***

Ярышлар Яшьлек ур. 3 нче йорт адресы буенча «ТР ЗМР иҗат үзәге» өстәмә белем бирү МБУ базасында үткәрелә, март. Команда составы 5 кеше (4 ир-ат, 1 хатын-кыз). «Көрәш балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ һәм «ТР ЗМР иҗат үзәге» өстәмә белем бирү МБУ үткәрү өчен җаваплы.

***5. ВОЛЕЙБОЛ.***

Ярышлар «Авангард» спорт комплексында, март-апрель көннәрендә уздырыла. Команда составы 10 кеше (5 ир-ат, 1 хатын - кыз). «4 нче балалар - яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ һәм «А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы» АҖ, «ТР ЗМР иҗат үзәге» өстәмә белем бирү МБУ үткәрү өчен җаваплы.

***6. ЙӨЗҮ.***

Ярышлар «Метеор» СОК» МАУ, апрель айларында уздырыла. Команданың составы 10 кеше (6 ир-ат, 4 хатын-кыз). «Дельфин» 5 нче балалар - яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ һәм «Метеор» СОК» МАУ үткәргән өчен җаваплы.

***7. ҖИҢЕЛ АТЛЕТИКА.***

Ярышлар В.Колотов исемендәге «Комсомолец» стадионында, май аенда уздырыла. Команда составы 10 кеше (6 ир-ат, 4 хатын-кыз). «4 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә һөнәри белем бирү МБУ һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе үткәрү өчен җаваплы.

***8. «ХЕЗМӘТКӘ ҺӘМ ОБОРОНАГА ӘЗЕР» БӨТЕНРОССИЯ ФИЗКУЛЬТУРА-СПОРТ КОМПЛЕКСЫНЫҢ ҖӘЙГЕ ФЕСТИВАЛЕ***

Ярышлар В.Колотов исемендәге «Комсомолец» стадионында, августта уздырыла. Команданың составы 10 кеше (6 ир-ат, 4 хатын-кыз). «3 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ, «4 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» ДБУ, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе үткәрү өчен җаваплы.

***9. МИНИ-ФУТБОЛ.***

Ярышлар В.Колотов исемендәге «Комсомолец» стадионында, сентябрь көннәрендә уздырыла. Команда составы 10 кеше. (10 ир-ат). «3 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ, «Серго исемендәге завод» ҖБ» АҖ үткәрү өчен җаваплы.

***10. ШАШКИ.***

Ярышлар «Дельфин» 5 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ, октябрь аенда үткәрелә. Команда составы 6 кеше (4 ир-ат, 2

хатын-кыз). Команда составы 4 кеше (3 ир-ат, 1 хатын-кыз). «Дельфин» 5 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ үткәрү өчен җаваплы.

***11. ШАХМАТЛАР.***

Ярышлар «Дельфин» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ шахмат мәктәбендә, ноябрь аенда уздырыла. Команда составы 4 кеше (3 ир-ат, 1 хатын-кыз). «Дельфин» 5 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» өстәмә белем бирү МБУ үткәрү өчен җаваплы.

## 4.СПАРТАКИАДАДА КАТНАШУЧЫЛАР.

Ярышларда предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар коллективларының тиешле физик әзерлеге һәм табиб рөхсәте булган хезмәткәрләреннән торган җыелма командалары катнаша ала. Бер коллективтан командалар саны чикләнмәгән (иң яхшы команда нәтиҗәсе буенча -зачет ). Ярышларда катнашучыларның әлеге коллективка караганлыгын раслый торган документлар булырга тиеш. Аз санлы хезмәткәрләре булган коллективлар ведомствога караган җыелма командалар белән берләшә ала.

Спартакиаданың барлык ярышларында шәхси һәм команда зачетында чыгыш ясарга теләүче җыелма командалар катнаша ала, әмма аларның нәтиҗәсе Спартакиаданың гомуми зачетына кертелми.

## 5. ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ БИЛГЕЛӘҮ ҺӘМ БҮЛӘКЛӘҮ.

Спартакиаданың һәр төрендә 1 урын өчен командага 30 очко, 2 урын өчен - 28 очко, 3 урын өчен - 26 очко, 4 урын өчен - 24 очко, 5 урын өчен - 23 очко һ.б. Җиңүче җыелган очколарның иң күп суммасыннан чыгып билгеләнә.

Спартакиаданың аерым төрләрендә 1 урынны алган командалар Кубоклар, 1 дәрәҗә дипломнар, кыйммәтле яки акчалата призлар, медальләр белән бүләкләнә. 2, 3 урыннарны алган командалар һәм катнашучылар тиешле дәрәҗәдәге дипломнар, медальләр белән бүләкләнә .

Спартакиаданың барлык төрләре дә зачет санала. Спартакиадада иң күп сандагы очко җыйган команда Кубок, 1 дәрәҗә диплом һәм кыйммәтле приз белән бүләкләнә. 2, 3 урынны алган командалар тиешле дәрәҗәле дипломнар белән бүләкләнә.(бүләкләү өчен җаваплы - Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе). Баллар саны тигез булганда, җиңүче призлы урыннарның иң күп саны буенча билгеләнә: 1 нче, аннары 2 нче һ. б.

## 6.ФИНАНС ЧЫГЫМНАРЫ.

Спартакиаданы оештыру һәм үткәрү, катнашучыларны һәм командаларны бүләкләү белән бәйле чыгымнар Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе һәм аның структур бүлекчәләре хисабына гамәлгә ашырыла.

## 7.ЗАЯВКАЛАР.

Оешма җитәкчесе һәм табиб тарафыннан расланган һәр спорт төре буенча исемле заявкалар, билгеләнгән формага ярашлы рәвештә, Ленин ур., 5 адресы буенча команда вәкилләре киңәшмәсе көнне Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсенә тапшырыла.

Белешмәләр өчен телефон: 8(84371) 4-67-93.